# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Административ хокук бозулар турында**
**Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2009 елның 3 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында 2006 елның 19 декабрендәге 80-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2; Ватаным Татарстан, 2009, 1 август, 24 октябрь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 бүлек исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3 бүлек. **Әйләнә-тирә табигать мохитен саклау, төзекләндерү, су объектларында җәмәгать тәртибен саклау һәм кешеләр гомерен саклау өлкәсендә административ хокук бозулар**";

2) 3 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 3.10 статья өстәргә:

"3.10 статья. **Татарстан Республикасы территориясендә су объектларында кешеләр гомерен саклау кагыйдәләрен бозу**

Татарстан Республикасы территориясендә су объектларында кешеләр гомерен саклау кагыйдәләрен бозган өчен –

кисәтү ясала яисә гражданнарга – өч йөздән алып биш йөз сумга кадәр; вазыйфаи затларга – дүрт меңнән алып биш мең сумга кадәр; юридик затларга кырык меңнән алып илле мең сумга кадәр административ штраф салына.";

3) 7.1 статьяда "3.9" санын "3.10" санына алмаштырырга;

4) 8.1 статьяда:

а) икенче өлештә "2.1 – 2.5, 2.8, 2.9, 3.2, 3.4 – 3.9, 4.3, 4.4 статьяларында" сүзләрен "2.1 – 2.5, 2.8, 2.9, 3.2, 3.4 – 3.9, 3.10 (гражданнарга карата), 4.3, 4.4 статьяларында" сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле җиденче өлеш өстәргә:

"Әлеге статьяның беренче һәм икенче өлешләрендә каралган очраклардан тыш, әлеге Кодексның 3.10 статьясында (вазыйфаи һәм юридик затларга карата) каралган административ хокук бозулар турындагы беркетмәләрне төзергә түбәндәгеләр хокуклы:

Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министры, аның урынбасарлары;

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының структур бүлекчәләре һәм территориаль органнары белгечләре.";

в) җиденче өлешне сигезенче өлеш дип санарга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — М.Ш. Шәймиев

Казан, Кремль
2009 елның 26 декабре
№ 70-ТРЗ